Бүгенге санда:



Әлегә футбол кырында көч сынаштылар. 2 бит


# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Чәршәмбе 17 июнь 2015 ел

№ 43 (10572)


**18 июньгә һава торышы:** аязучан болытлы һава, җил көньяк-көнбатыштан 1-5 м/с; температура көндез +34°С, төнлә +23°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## Абзац-информ

### САЙЛАУЛАР КӨНЕ БИЛГЕЛӘНДЕ

Нурлат шәһәре Советының чираттагы 40нчы сессиясендә Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советына депутатлар сайлау срогы билгеләнде. Депутатлар аны тиешле законнарга таянып, 2015 елның 13 сентябре дип хәл иттеләр. Нурлат шәһәре Советы рәисе, район башлыгы Равил Кузюров җитәкчелегендә барган сессиядә Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре башкарма комитетлары арасында, җирдән файдалану һәм шәһәр төзелеше буенча расланган кагыйдәләр булган очракта, дәүләти милек чикләнмәгән һәм шәһәр территориясендә урнашкан җир участоклары белән идарә итүдә хезмәттәшлек турында килешү расланды.

### ИЗГЕ СӘФӘР

Якшәмбе көнне узган Изге Болгар җыенында Нурлаттан да район мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов җитәкчелегендәге делегация катнашты.

- Алдагы көнне Россиядә Ислам үсешенә багышланган форум эшендә булдым, - диде район мөхтәсибе әлеге мөһим чара турында кыскача мәгълүмат җиткереп. – Чарага барган 100гә якын нурлатлы изге урынга сәяхәт белән беррәттән, өйлә намазында да катнаштылар.

### ПРИЗЫВНИКЛАР ЯНЫНДА

Язгы чакырылыш кампаниясе кысаларында ТРда кеше хокукларын яклау буенча уполномоченныйның Нурлат районындагы ярдәмчесе Идрис Кәримов Саратов өлкәсенә командировкага китте. Ул бүген республикадан олы юлга кузгалган 22 солдатны озата барачак. Моннан тыш, омбудсмен әлеге частьта срочный хезмәт узучы Татарстан егетләре белән дә очрашачак. Солдатларның хезмәт шартлары белән танышып, кеше хокукларын яклау законының үтәлешен дә тикшерәчәк.

### ЕЛГА БУЕ ЧИСТАРТЫЛДЫ

"Татарстанда чиста булачак!" республика хәрәкәте киңкырлы марафонының 12 июньдә узган II этабында Заречный авылындагы Зур Чирмешән елгасы яр буйлары чистартылды. Чисталык акциясенең чираттагы этабы да мәктәп укучылары катнашында узды.

– Өмә барышында "Заречный" сәламәтләндерү лагере территориясендәге елга ярларын чистарттык, - ди районның баш экологы Рөстәм Ногманов. – Нәтиҗәләр сөендерерлек: елга яры без көткәннән чистарак булып чыкты. Кешеләр шулай үзләре яшәгән урынны чистартып, карап торсыннар иде. Шул вакытта тырышлык та югалмас, тирә – юнь дә чиста булыр.

# Артур Миквабия:" *Безнең очрашу – дуслык мөнәсәбәтләренә яңа импульс*"




КУНАКЛАР АТ ЗАВОДЫН ДА КАРАДЫЛАР

**12 июнь, Россия көнендә Нурлат районында Абхазия Республикасы премьер-министры Артур Миквабия, Татарстан Республикасы вице-премьеры Васыйл Шәйхразиев, Россия Дәүләт Думасы депутаты Фатыйх Сибагатуллин булып киттеләр.**

Вертолет мәйданчыгында мәртәбәле кунакларны район башлыгы Равил Кузюров каршы алды. Аның озатуында делегация район белән танышуны Кама аръягы һәм Нурлат шәһәре тарихы музееннан башлады. Биредә Артур Артемович төбәкнең бай тарихына игътибар итте. Васыйл Гаязович белән алар Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган экспозиция янында озаклап тукталдылар.

– Фронт елларында Нурлатта хәрби госпиталь, завод эшләгән, – дип тарихка экскурс ясап алды район башлыгы. Шунда ук Премьер-министр ТАССРның сугышчан чакыруга кушылып фронт өчен шактый суммада акча җыюын да искәртеп алды.

Аннан кунаклар Боз сараена күчтеләр, анда аренаның эшләвен карадылар. Биредә хоккейчылар күнегүләр үткәрә иделәр. Сөйләшү барышында Абхазиянең Премьер-министры мондый социаль әһәмиятле объектларны төзү буенча сорау биреп алды. Делегация караган тагы бер социаль объект – "Чияле Алан" ял лагере иде. Балалар кунакларны җыр-бию белән каршы алдылар: район кунаклары "Татнефть" тарафыннан төзелгән әлеге лагерьга югары бәя бирделәр.

Артур Миквабия сәфәрләренең максатын иң беренче чиратта Татарстан һәм Абхазия арасындагы дуслык элемтәләренә яңа импульс бирү, дип билгеләде.

– Безнең арада үзара хезмәттәшлек турында Килешү төзелгән. Республикаларны ныклы дуслык элемтәләре бәйли. Бездә хәрби конфликтлар баш күтәргәндә, Татарстанның нинди ярдәм күрсәткәнлеген әле дә хәтерлибез. Татарстан тиз һәм ныклы үсештә. Сезгә кыска вакытлы визит барышында мин мөмкин кадәр күбрәк белергә теләдем. Сезнең районда яшь һәм энергияле җитәкче, сез заман белән бергә атлыйсыз, – диде үз сәфәре ахырында Абхазия Премьер-министры.

Сәфәр Югары Нурлатта ат чабышын карау белән тәмамланды. Биредә кунакларны атларны асрау һәм чабышкылар әзерләү дәрәҗәсе һәм алар ирешкән җиңүләр чын-чынлап сокландырды һәм гаҗәпләндерде.

Валентина ВАФИНА




## "ДУСЛЫК"КА ЯЗЫЛЫП БҮЛӘК ОТ!

15 июньнән 25енә кадәр почта бүлекчәләрендә һәм редакциябездә киләсе яртыеллыкка район газетасына язылыгыз һәм турыдан-туры Зур БҮЛӘКЛӘР УЙНАТУДА катнашып, 20дән артык призыбызның берсен отыгыз!

Призлар фондында электр чәйнеге, кофе тарткыч, вентилятор, су фильтры, миксер, фен, одеял, блендер, чәй сервизы, савыт-саба, сөлгеләр җыелмасы, плед, сәламәтлек клубына сертификатлар һәм башка күп нәрсә бар.

Әбунә тәмамланырга нибары 2 атна вакыт калып бара. Соңга кала күрмәгез!

## РАЙОН ТОРМЫШЫ

# Бердәмросслар футбол кырында да сынатмады

**12 июнь – Россия көнендә шикәрчеләр микрорайоны стадионында гадәти булмаган футбол матчы үтте.**

Аны "Бердәм Россия" партиясенең Нурлат җирле бүлекчәсе республикада бердәм булып үткән "Прайм-лига" кысаларында оештырды.

Матчның гадәти булмавының сере – футбол кырында иптәшләрчә очрашуга чыккан командалар составының үзенчәлекле булуында. Районда муниципаль сайлауларга әзерлек кысаларында 27 мәйданчыкта үткән праймеризларда катнашучылар командасын бүлекчә секретаре, район башлыгы Равил Кузюров үзе җитәкләвен һәм беренче тайм азагына кадәр алгы сызыкта һөҗүмдә уйнавын гына күр син. Команда составында мәктәп директорлары Анатолий Евлентьев, Солтан Әхмәтҗанов, "Нурлатнефть" НГДУсының профком рәисе Ринат Мөхәммәтҗанов, "Нурлат шикәре" җәмгыяте генераль директоры Игорь Сагайдак, 94нче даруханә мөдире Илдар Зәкуанов, "Экодом" идарәче компаниясе җитәкчесе Илфат Гәрәев һәм башка бик күп җитәкчеләр булуы исә җанатарларның матчка карата кызыксынуын арттырды гына. Икенче команданың составын нигездә праймеризларда сайлаучылар булып катнашкан уенчылар тәшкил итте, җирле массакүләм-мәгълүмат чаралары вәкилләре дә бар иде. "Прайм-лига" моннан 4 ел элек РФ Дәүләт Думасына сайлауларга әзерлек чорында беренче тапкыр оешкан иде. Быел исә ул 1 июньдә төгәлләнгән праймеризларга багышланды.

Стадионда матч башланганчы ук зур активлык сизелде, районның мәдәният хезмәткәрләре җыелучыларга бәйрәм концерты тәкъдим итте, футбол матчын карарга шәһәрдән генә түгел, авыллардан да килүчеләр шактый иде. Мәктәп лагерьларенда, "Нурсан"да ял итүче балалар да уенны азагына кадәр кызыксынып күзәттеләр. "Президент белән бергә!" хәрәкәте активистлары оештырган "Спортивный Татарстан" мәйданчыгында төрле оешма-предприятие, учреждение вәкилләре ГТО нормалары тапшырдылар.



УЕННЫҢ НӘТИҖӘСЕН ПЕНАЛЬТИДАН КЕРТЕЛГӘН ГОЛ ХӘЛ ИТТЕ

– ГТО тапшыру өчен менә дигән мөмкинлек булды. Үз көчемне урыннан сикерү, отжимание, гер күтәрү кебек төрләрдә сынап карадым, - ди "Нурлат УТТ"сының ПТО начальнигы Алексей Федоров.

Шунда ук бер төркем үсмергә Россия гражданнары паспортлары тапшыру да оештырылды.

– Паспортны Россия көнендә һәм район башлыгы Равил Кузюровның үз кулыннан алу аеруча дулкынландыргыч булды. Мин паспортымны зур горурлык белән йөртәчәкмен, - ди Фома мәктәбе укучысы Фидалия Гайфуллина.

Ул да түгел, стадионда уен башланып китте. Өстенлек исә әле бер, әле икенче командa ягында булды.

– Уен бик киеренке бара, көчләр тигез диярлек, – дип тәэсирләре белән уртаклашты беренче таймнан соң район башлыгы Равил Кузюров һәм алга таба мондый уеннарны үткәрү өчен шәһәрнең яңа стадионын өлгертергә тырышачакларын әйтте. Ә чараны тантаналы ачу вакытында шикәрчеләр микрорайоны стадионында даими рәвештә уеннар үткәреп торучы футболчылар өчен дә сөенерлек хәбәр җиткерде: биредә дә йөгерү юллары, газонны яңарту планлаштырыла.

Беренче тайм азагында сайлаучылар капкасына билгеләнгән 11 метры пенальтидан бүлекчә секретаре Равил Кузюров керткән гол исә уенның нәтиҗәсен хәл итте. Исәп "кандидатлар" файдасына 1:0 белән тәмамланды.

Сайлаучылар җиңелсәләр дә, кәефләрен төшермәделәр. Чөнки уен иптәшләрчә халәттә, зур бәйрәм булып узды бит. Аннан, сәяси кырда сынатмаган "Бердәм Россия"нең футбол стадионында сер бирмәсенә күпләр баштан ук ышанган иде инде.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

### САН

**Республикада муниципаль праймеризлар 924 мәйданчыкта, 12 мең кандидат һәм 37 мең сайлаучы катнашында үтте. Президент праймеризы Казанда 27 июньгә билгеләнгән, анда 1636 сайлаучы катнашыр дип көтелә.**

### ХӘБӘРЛӘР

## САЙЛАУГА ӘЗЕРЛӘНӘЛӘР

**Узган атнада Мәдәният сараенда шәһәр һәм районның участок сайлау комиссияләре әгъзалары өчен уку үтте.**

Шәһәр территориаль сайлау комиссиясе рәисе Линар Маняпов җыелучыларны 2015нче ел сайлау кампаниясенең төп этаплары белән таныштырды, муниципаль берәмлекләрдә сайлауларның бермандатлы округлар буенча үтәсен аерым билгеләп узды. Район территориаль сайлау комиссиясе рәисе Лилия Шакирова слайдлар ярдәмендә республика үзәк сайлау комиссиясе әзерләгән методик материалны тәкъдим итте. Анда участок сайлау комиссияләренең вәкаләтләре, сайлаучыларга мәгълүмат җиткерү, мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм шикаятьләр кабул итү һәм аларны карау тәртибенә кагылышлы төп мәсьәләләр каралды.

– 2015 елның 13 сентябре – Бердәм тавыш бирү көнендә участок сайлау комиссияләре әгъзалары сайлаулар турындагы законнар тарафыннан билгеләнгән нормаларның үтәлеше өчен җаваплылыкны үз өсләренә алырга әзер, - дип йомгак ясады Линар Нурисламович.

**Валентина ВАФИНА**

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, РАМАЗАН!

**Иртәгә, 18 июньдә барлык мөселман дөньясы Рамазаен аена аяк баса. Бүген, 17 июньдә районыбызның барлык мәчетләрендә дә беренче тәравих намазлары башлана.**

Һиҗри календаре буенча ел озынлыгы бераз бераз кыскарак булу сәбәпле, изге ай ел саен 11-12 көнгә артка чигенә. Мөселманнарга тәүлек дәвамында унтугыз-егерме сәгать ашамыйча-эчмичә үткәрү, нәфес теләкләрен йөгәнләп тору җиңел булмас. Әмма тәвәккәлләп уразага кергән кешегә Аллаһы Тәгалә үзе ярдәмен бирә.

- Ислам дине буенча ураза – иң әһәмиятле гыйбадәтләрнең берсе, - ди район мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов. – Ураза тоту – ашау-эчүдән һәм башкалардан гына тыелып тору түгел. Шушы гыйбәдәткә керешкән мөселманнарның теле дә, күзе дә, кулы да, колагы да уразада булырга тиеш. Изге айда кылынган гыйбадәтләрнең саваплары әйтеп бетергесез. Изге айда тоткан уразаларыбыз, укыган намазларыбыз, биргән сәдакаларыбыз кабул булсын.

Мөхтәсибәттә әйтүләренчә, Рамазан аеның беренче көнендә сәхәр төнге 1нче яртыда тәмамлана, ә авыз ачу 21.45 сәгатьтә.

**Зилия ӘКСАНОВА**

# Юбилярны котладылар



**Дүшәмбе көнне үзенең 90 яшьлек юбилеен билгеләп узган Бөек Ватан сугышы ветераны Николай Кудряшов гомер бәйрәме уңаеннан Россия Президенты һәм район башлыгының котлауларын кабул итте. Юбилярны туган көне белән район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова котлап, аңа бүләкләр тапшырды.**

- Күз тимәсен, - диде район башлыгы урынбасары юбилярның күңел күтәренкелегенә сөенеп. – Олы яшьтә шундый оптимист булып калу үзе зур бәхет.

Николай Андреевичны тормыш төрле яклап сынаса да, ул бирешмәскә тырыша. Сугыш яралары, баласын югалту хәсрәтләре, нефтьче хезмәтенең кыенлыклары... Шундый авыр минутларында ул кулына баянын ала, я булмаса аучылык һәм балыкчылык белән мавыга. Тормыш иптәше Нина Ивановна белән бергә 69 ел гомер кичереп, 3 баланы тормыш юлына бастыралар. 6 оныгына һәм 6 оныкчыгына шөкерана кылып яшиләр. Ә үзләренең озын гомерле булуларын Кудряшовлар дөрес тормыш алып баруларында күрәләр.

**Зилия ӘКСАНОВА**

**Совет города Нурлат Нурлатского муниципального района Республики Татарстан**

**РЕШЕНИЕ**

№ 172 16 июня 2015 года

**О назначении выборов депутатов Совета города Нурлат Нурлатского муниципального района Республики Татарстан третьего созыва**

В соответствии с пунктами 3, 7 статьи 10 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», частью 2 статьи 6, частью 1 статьи 105 Избирательного кодекса Республики Татарстан, статьи 12consultantplus://offline/ref=1177C02C54AC96C721B21778DAEC07347A3BB2222D3124739F373D5525D6F6D16A74344FEFE8E0AE7AE4B6R1p6J Устава муниципального образования «город Нурлат», Совет города Нурлат Нурлатского муниципального района, **РЕШИЛ**:

1. Назначить выборы депутатов Совета города Нурлат Нурлатского муниципального района Республики Татарстан третьего созыва на 13 сентября 2015 года.

2. Опубликовать настоящее Решение, не позднее чем через пять дней со дня его принятия, в том числе на официальном сайте Нурлатского муниципального района Республики Татарстан.

**Председатель Совета города Нурлат Нурлатского муниципального района Р.А. Кузюров**

**Решения Советов сельских поселений Нурлатского муниципального района Республики Татарстан**

**О назначении выборов депутатов Советов сельских поселений Нурлатского муниципального района Республики Татарстан** третьего созыва на 13 сентября 2015 года

1. Амзинское сельское поселение (решение Совета Амзинского сельского поселения от 15.06.2015 № 97)
2. Андреевское сельское поселение (решение Совета Андреевского сельского поселения от 15.06.2015 № 128)
3. Ахметовское сельское поселение (решение Совета Ахметовского сельского поселения от 15.06.2015 № 133)
4. Бикуловское сельское поселение (решение Совета Бикуловского сельского поселения от 15.06.2015 № 105)
5. Биляр-озерское сельское поселение (решение Совета Биляр-Озерского сельского поселения от 15.06.2015 № 99)
6. Богдашкинское сельское поселение (решение Совета Богдашкинского сельского поселения от 15.06.2015 № 128)
7. Бурметьевское сельское поселение (решение Совета Бурметьевского сельского поселения от 15.06.2015 № 99)
8. Гайтанкинское сельское поселение (решение Совета Гайтанкинского сельского поселения от 15.06.2015 № 68)
9. Егоркинское сельское поселение (решение Совета Егоркинского сельского поселения от 15.06.2015 № 115)
10. Елаурское сельское поселение (решение Совета Елаурского сельского поселения от 15.06.2015 № 208)
11. Зареченское сельское поселение (решение Совета Зареченского сельского поселения от 15.06.2015 № 102)
12. Кичкальнинское сельское поселение (решение Совета Кичкальнинского сельского поселения от 15.06.2015 № 106)
13. Кульбаево-Марасинское сельское поселение (решение Совета Кульбаево-Марасинского сельского поселения от 15.06.2015 № 119)
14. Мамыковское сельское поселение (решение Совета Мамыковского сельского поселения от 15.06.2015 № 131)
15. Новоиглайкинское сельское поселение (решение Совета Новоиглайкинского сельского поселения от 15.06.2015 № 130)
16. Новотумбинское сельское поселение (решение Совета Новотумбинского сельского поселения от 15.06.2015 № 93)
17. Селенгушское сельское поселение (решение Совета Селенгушского сельского поселения от 15.06.2015 № 163)
18. Среднекамышлинское сельское поселение (решение Совета Среднекамышлинского сельского поселения от 15.06.2015 № 111)
19. Староальметьевское сельское поселение (решение Совета Староальметьевского сельского поселения от 15.06.2015 № 93)
20. Старочелнинское сельское поселение (решение Совета Старочелнинского сельского поселения от 15.06.2015 № 138)
21. Степноозерское сельское поселение (решение Совета Степноозерского сельского поселения от 15.06.2015 № 107)
22. Тимерлекское сельское поселение (решение Совета Тимерлекского сельского поселения от 15.06.2015 № 115)
23. Тюрнясевское сельское поселение (решение Совета Тюрнясевского сельского поселения от 15.06.2015 № 165)
24. Фомкинское сельское поселение (решение Совета Фомкинского сельского поселения от 15.06.2015 № 97)
25. Чулпановское сельское поселение (решение Совета Чулпановского сельского поселения от 15.06.2015 № 66)
26. Якушкинское сельское поселение (решение Совета Якушкинского сельского поселения от 15.06.2015 № 151)

**Карарларны кушымталары белән nurlat-tatarstan.ru сайтында карый аласыз.**

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## НЕДВИЖИМОСТЬ

*дом, ул. Советская, 117. Т. 8-927-243-65-08.
*дом на ж/д. Т. 8-927-414-73-53.
*комната в общежитии, 18 кв.м. Т. 8-937-616-53-18.
*земельный участок в п. Тарн-Варн, 15 соток. Т. 8-987-238-17-92. П/с 16-16-03/007/2006-349
*дом, ул. Дубравная, 44. Т. 8-927-248-87-85.
*дом, варианты. Т. 8-919-684-40-03.
*2-комнатная квартира в мкр. Яшлек, с гаражом. Т. 8-927-047-99-00.
*3-комнатная квартира, ул. Шашина. Т.: 8-927-474-46-16, 4-37-60.
*дом. Варианты. Т. 8-937-283-86-00.
*1-комнатная квартира в Самаре, 2 этаж 5ти этажного дома по ул. Гагарина, ст. метро Спортивная. Т. 8-927-757-07-46.
*дом по ул. Декабристов, 49. Т. 2-87-36.
*старый дом в п. Пушкино. Т. 8-927-405-76-25.
*дом. Т. 8-9274-31-48-09.
*1-комнатная квартира, ул. Гиматдинова, 630000 руб., 2-комнатная, центр, 1000000 руб., 3-комнатная, центр, 970000 руб., дом, с. Мамыково, 350000 руб., дом у реки с. Курманаево, 120000 руб., дом, ул. Фахрутдинова, 3000000 руб., недострой по ул. Ахметова, ул. Дальняя, ул. Куйбышева. Т. 8-937-600-47-73, Алсу.
*дом в д. Русская Менча. Т. 8-937-623-47-81.
*2-комнатные квартиры: ул. Гагарина, 2; ул. Гиматдинова, 80, недорого. Т. 8-929-727-12-82 (Ксения).
*2-комнатная квартира, ремонт, ул. Советская, 1050000 руб. Т. 8-929-727-12-82.
*новый коттедж, кирпич, 4050000 руб., торг; дом, ул. Кутузова, 1750000 руб. Т. 8-929-727-12-82.
*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 2 этаж. Т.: 8-927-241-02-11, 8-917-880-52-50.
*3-комнатная квартира, ул. Нурлатская, четная сторона, 3 этаж. Т. 8-927-414-73-53.
*дом, ж/д. Т. 8-927-428-21-12.
*срочно комната (малосемейка). Т. 8-927-047-10-21.
*1-комнатная квартира, 30,8 кв.м, ул. Советская. Т. 8-937-620-17-71
*1-комнатная квартира, ул. Советская, 187. Т. 8-927-036-64-96 (Йолдыз).
*жилой дом, с. Мамыково, 550000. Т. 8-987-183-42-69.
*1-комнатная квартира (малосемейка), 36 кв.м. Т. 8-937-589-51-74.
*дом, земельный участок, хоз.постройки, пос. Ключи. Т. 8-927-466-11-91.
*дом, 116,4 кв.м, ул. Михеева, 21. Цена договорная. Т. 8-927-249-25-35.
*жилой дом, ул. Красноармейская, гараж на две машины, баня, сарай, теплица, газ, вода. Т. 8-917-393-26-77.
*дом, с. Егоркино. Т. 8-937-441-07-56.
*дом, мкр. Верхний Нурлат. Т. 8-965-582-11-72.
*элитный коттедж, 210 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.
*земельный участок, ветхий дом, ул. Маслозаводская, 220000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, с/з, 1 этаж, без ремонта, 720000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой новый дом, д. Бурметьево, 650000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, 120 кв.м, центр, 1 этаж, баня, гараж, 3,8 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, ул. Кариева, 3 этаж, 70 кв.м, 1530000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 5 этаж, индивидуальное отопление. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, мансарда, 50 кв.м, 700000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*недостроенный дом, ул. Звездная, 31, 100 кв.м, 1 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, центр, 43 кв.м, 1 этаж, 920000 руб.. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, баня, гараж, 1850000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*1-комнатная квартира, центр, малогабаритная, 500000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*1-комнатная квартира, центр, 2 этаж, 600000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, д. Курманаево, 55 кв.м, 200000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, 50 кв.м, лоджия, 1280000 руб., 3 этаж, центр. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, 1 этаж, 50 кв.м, индивидуальное отопление. Т. 8-937-610-48-70.
*дом, мкр. Нижний Нурлат. Т.: 8-927-040-70-88, 8-927-476-42-51.
*2-комнатная квартира под бизнес. Т. 8-927-470-39-02.
*1-комнатная квартира, центр, 2 этаж, 32 кв.м. Т. 8-937-289-14-03.
*3-комнатная квартира, центр, 53,4 кв.м. Т. 8-937-289-14-02.
*1-комнатная квартира, с/з, 2 этаж. Т. 8-927-438-07-95.
*дом, ул. Мира. Т. 8-917-397-00-48.
*1-комнатная квартира по ул. Хамадеева, с мебелью. Т. 8-927-721-73-10.
*2-комнатная квартира, центр. Т. 8-937-291-77-88.
*дом, с. Бутаиха, 300000 руб. Т. 8-927-422-24-56.

## АВТОТРАНСПОРТ

*«Дэу Матиз», 2009 г/в. Т.: 8-929-725-03-93, 8-917-289-62-95.
*«Джили Эмгрант», люкс, срочно. Т. 8-927-671-74-78.
*«Лада Калина», 2007 г/в, в хорошем состоянии. Т. 8-927-433-14-54.
*«ВАЗ-2107», 2002 г/в, в хорошем состоянии. Т. 8-927-457-99-61.
*«ВАЗ-21154», в хорошем состоянии, 2008 г/в. Т. 8-927-458-17-84.
*«УАЗ-4696», 2008 г/в, полный капремонт, 150000. Т. 8-952-046-02-31.
*«ИЖ-2126030», 2002 г/в. Т. 2-84-11.
*«Калина», универсал, 2011 г/в. Т. 8-937-773-92-92.
*«ВАЗ-211440», пробег 47000. Т. 8-937-525-60-85.
*«Дэу Матиз», 2011 г/в, черный, пробег 40000. Т. 8-927-498-05-39.
*«Дэу Матиз», 2008 г/в, автомат. Т. 8-987-060-60-03.
*«Нива-212140», 2008 г/в, 200 тыс. руб., торг. Т. 8-937-77-66-359.
*«УАЗ-469Б», 100 тыс. руб., торг. Т. 8-937-77-66-359.
*срочно «Ленд Ровер Фреланд», 2005 г/в. Т. 8-917-282-30-23.
*срочно «ГАЗ-53», самосвал, 55000 руб. Т. 8-927-443-64-44.
*«Приора», хэтчбек, 2014 г/в, 320000 руб. Т. 8-927-444-70-17.
*«ВАЗ-211440», 2010 г/в, цвет черный, в идеальном состоянии, цена 163000. Т. 8-927-48-000-74.
*«ВАЗ-2107», 2009 г/в, 60000 руб. Т. 8-927-481-30-38.
*«Нива», 1998 г/в. Т. 8-927-457-78-02.

## ДРУГОЕ

*бут, ПГС, песок. Т. 8-917-876-98-15.
*куры-молодки. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.
*бычки с племхозяйства. Т. 8-937-453-40-91.
*Семена костер, люцерны. Т. 8-927-470-39-02.
*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.
*бычки (молодняк). Т. 8-927-870-49-62.
*индюшата, бройлеры, муларды, утята, гусята. Т. 8-927-419-12-00.
*реализуем 1-, 2-месячных: индейка HybridConverter, гусята, утята муларды, бройлеры в пгт. Алексеевское. Т.: 8-905-020-83-38, 8-905-345-79-70.
*пчелы. Т. 8-927-453-74-80.
*песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.
*вощина ульяновская, 420 руб./кг. Обмен на воск. Т. 8-927-751-61-46.
*перегной, чернозем. Т. 8-9274-636-317.
*песок, бут, ПГС, щебень, цемент. Т. 8-927-401-51-91.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-927-247-27-37.
*дрова. Т. 8-937-003-27-27.
*корова. Т. 8-937-610-69-45.
*б/у швеллера, ширина 12, 27, цена договорная. Т. 8-937-584-53-13.
*корова первотелка. Т. 8-937-290-31-94.
*ПГС, щебень, песок, ОПГС. Услуги «КамАЗ». Т.: 8-987-228-43-43, 8-986-718-12-84.
*говядина молодняк по частям и кусками. Т. 8-927-245-32-03.
*телята, стельная корова. Т. 8-927-460-96-30.
*ПГС! Бут! Песок! От 1 кг. Т. 8-9274-222-666.
*дрова. Т. 8-927-414-61-34.
*дрова. Т. 8-987-213-32-95.
*керамзит, керамблоки. Т. 8-927-247-85-89.
*дрова. Т. 8-987-213-32-95.
*ПГС, бут, песок, чернозем. Т. 8-937-615-97-30.
*новые гаражные ворота. Т. 8-927-422-20-47.
*дрова чурбаками и колотые. Т. 8-937-775-21-68.
*овцы. Т. 8-937-297-02-44.
*каменный уголь. Т. 8-927-487-27-60.
*шифер, б/у. Т. 8-987-422-50-83.
*ПГС, бут, песок. Т.: 8-927-248-19-66, 8-917-248-21-66.
*банные печи. Т. 8-927-474-03-22.
*шикарное свадебное платье, размер 42-46, перчатки в подарок, торг уместен. Т. 8-937-616-06-20.
*ООО «Спецэнергомонтаж» реализует тротуарную плитку – клевер, краковская, прямоугольная по 480 руб. кв.м; блоки из цельного керамзита фракции 5-10 по 41 руб. за 1 шт. Обращаться: пер. Заводской, 1а (ЖБИ), тел.: 2-50-90, 2-66-75.
*гараж на санях. Т. 8-927-489-36-41.
*корова, 3 отела, на мясо. Т. 8-927-472-60-73.
*электроводонагреватель, хлебопечь, памперсы для взрослых. Т. 8-927-033-76-28.
*дойная корова. Т. 8-927-474-21-02.
*семена – костер, люцерна. Т. 8-927-470-39-02.
*картошка. Т.: 8-9600-38-75-33, 3-98-17.
*козье молоко. Т. 8-927-402-60-91.
*холодильник. Т. 8-927-676-54-92.
*железная дверь. Т. 8-927-444-70-17.
*сруб бани. Т. 8-917-262-72-94.
*стиральная машина «Фея» (в упаковке), стол раздвижной. Т. 8-927-043-67-22.
*взрослый городской велосипед, новый, с замком. Т. 8-917-251-46-74.
*оконные рамы, б/у; старые доски, дешево. Т. 8-929-723-19-49.
*вагончики 2,80х2,80, 2,80х6,00, утепленные. Т. 8-927-431-59-78.
*козье молоко. Т. 8-927-443-76-66.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-987-413-91-33.

## РАЗНОЕ

*Йомшак жиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.
*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.
*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.
*такси Нурлат-Самара, ежедневно из дома. Т. 8-927-673-79-46.
*ремонт холодильников. Т. 8-927-419-56-48.
*кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.
*тамада. Т. 8-965-620-01-67.
*мечеть на с/з примет в дар холодильник.
*возьму щенка (кобель). Т. 8-927-448-63-05.
*копаем, заливаем фундамент, копаем траншеи и канализации, чистим колодцы. Качественно, вручную. Т.: 8-937-589-51-73, 8-987-274-95-46.
*сантехника (вода, канализация, отопление). Т. 8-937-526-56-86.
*покрытие ванн акрилом. Т. 8-987-409-98-49.
*ищу работу – экономист-аудитор. Образование высшее – Московский институт Сервиса. Стаж работы 20 лет. Сфера – строительство, бюджет. Т. 8-937-611-39-59.
*ремонт стиральных машин. Т. 8-927-468-16-31.
*установка окон, дверей, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.
*сварочные услуги. Т. 8-987-278-51-77.
*замена электропроводки. Т. 8-929-728-93-36.
*помощь компьютеру. Т. 8-909-308-22-56.

## ТРЕБУЕТСЯ

*парикмахеры. Т. 8-927-403-91-39.
*организации рабочие. Т. 8-937-771-55-14.
*для работы на установке подготовки нефти оператор товарный, слесарь по ремонту технологических установок, электрогазосварщик, электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования, старший мастер по подготовке нефти, ведущий метролог. Обращаться по тел.: 8(8553) 39-39-90, 39-30-92, 8-917-870-00-88.
*продавцы, водитель, грузчик. Т. 8-927-445-68-55.
*ООО «Агро порт» временные рабочие. Т.: 2-09-82, 8-937-528-43-59.
*на кирпичный завод водитель на карьерный «КамАЗ-55111». Т.: 4-00-68, 8-917-871-41-19.
*водитель в нурлатское райпо. Т. 8-937-620-04-26.
*повар. Т. 8-927-427-79-97.
*в организацию электросварщики I уровня НГДО с опытом работы не менее 3-х лет. Зарплата высокая. Тел. 2-81-58. Адрес: г.Нурлат, ул. Советская, 148.
*газорезчики, грузчики. Т.: 8-927-438-54-95, 8-927-428-83-88.
*массажист. Т.: 2-43-03, 2-43-04.
*ООО «СК Регион» мастер участка водонасосной установки, з/п от 25000 руб. Т. 2-03-08.
*ухаживающий за пожилой женщиной. Т.: 8-937-592-12-41, 2-59-16.
*Нурлатскому участку ЦЭО ООО «Бурение» бурильщик эксплуатационного и разведочного бурения скважин на нефть и газ; электромонтер по ремонту и обслуживанию электрооборудования; слесарь КИП и А; слесарь-ремонтник. По вопросам трудоустройства обращаться в отдел кадров по адресу: г.Нурлат, ул. Советская, 130, тел. 92-2-60.

## КУПЛЮ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.
*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.
*баллоны кислородные, углекислотные. Т. 8-987-292-01-10. ООО «ГК «Втормет».
*КРС, шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-412-29-99.
*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.
*дешево автоприцеп на легковую а/м, б/у. Т. 8-937-296-94-03.
*КРС. Т. 8-927-481-30-38.

## ОБМЕН

*жилой дом на ж/д на квартиру. Т. 8-9270-40-67-09.

## ПОТЕРИ


*водительское удостоверение на имя Василия Николаевича Яллина просим вернуть за вознаграждение. Т. 8-937-600-13-09.
*паспорт на имя Ильнара Минахметовича Гареева прошу вернуть за вознаграждение. Т. 8-9274-28-24-44.

## СДАЮТСЯ

*в парикмахерской рабочие места. Т. 8-937-287-68-88.
*помещения под офис. Т. 8-927-247-94-76.
*квартира посуточно. Т. 8-927-456-05-69.
*1-комнатная квартира в районе сахарного завода. Т. 8-927-497-81-94.
*1-комнатная квартира. Т. 8-927-673-89-44.
*1-комнатную квартиру. Т. 8-937-600-49-53.
*квартира. Т. 8-937-285-79-84.
*1-комнатная квартира. Т. 8-937-593-98-12.
*в аренду офисное помещение. Адрес: г.Нурлат, ул. Советская, 75. Т. 2-32-99.
*помещение, мкр. Яшлек. Т. 8-9272-48-48-04.


**ВНИМАНИЕ!!!**

**Только с 1 по 30 июня**
Компания "Оконные системы"




**Окно 1300х1400**
Подоконник 300 мм
Отлив 150мм
Монтаж с демонтажем
При заказе более 2-х окон:
**ПОДАРОК до 1000р с окна***

| Rehau | KBE | Montblanc | Exprof |
|---|---|---|---|
| 7700 руб | 7200 руб | 6500 руб | 6000 руб |

**т. 8-927-742-66-67, 8-908-383-89-98**
*Подробности по указанным телефонам. Организатор: ООО "СВК". Реклама


## Кайгы уртаклашабыз!

**«Чулпан» ИК АҖнең Нурлат филиалы коллективы һәм шәхсән аның директоры Дамир Нәгыйм улы Вәлиев**, әнисе вафат булу сәбәпле, "Чулпан" ИК АҖ генераль директоры **Фәрит Салих улы Вафин** гаиләсендәге авыр югалту кайгысын ихлас күңелдән уртаклашалар.
Якын кешеңне югалту хәсрәтен киметә алырлык сүзләр табу кыен. Кадерле хатын, сөекле әни һәм әби булып үз тирәсенә барлык якыннарын туплап торган кешесен югалткан гаиләне аның турындагы хатирәләр һәрчак җылытып торыр, ул һәрчак күңел түрендә яшәр. Бу авыр сәгатьтә без дә Сезнең белән кайгырабыз, хәсрәтегезне уртаклашабыз, авыр көннәрегездә түземлек һәм сабырлык телибез.

**УВАЖАЕМЫЕ АБОНЕНТЫ ЭПУ «НУРЛАТГАЗ»!**
С 01.07.2015г. в соответствии с Постановлением Государственного Комитета РТ по тарифам №4-1/г от 15.05.2015г., розничная цена 1куб.м газа для населения составит 5,16 руб.
Администрация ЭПУ «Нурлатгаз».





**ДОКТОР ОПТИКА**
*НАБИРАЕМ ОЧКИ!*
Только с 1 по 30 июня в салоне ДОКТОР ОПТИКА при покупке двух солнцезащитных очков - третьи в подарок!

Адреса салонов:
ул. Советская, 120 тел. (84345) 2-17-88, 8-927-427-79-27
ул. Гиматдинова, 81 тел. (84345) 2-91-99, 8-937-610-69-30
ТЦ Шифа, 1этаж тел. 8-927-246-56-55
ТЦ Радуга, 2 этаж тел. 8-937-613-99-88

*Подробности акции спрашивайте у продавцов-консультантов. Организатор акции: ИП Шабаева А.З. Лиц. №16-01-000675 от 13.12.2007г., выд. Фед.службой по надзору в сфере здравоохранения и соц.развития.
Реклама
ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ.НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА.



Гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" АҖ www.tatmedia.ru www.nurlat-tat.ru Реклама хезмәте телефоны: 8 (84345) 2-36-12

"Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы
Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

"Татмедиа" АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир С.Н. Хәйруллина
Тел.: 2-36-14

**Редакциянең адресы:**
423040, ТР, Нурлат шәһәре, К.Маркс ур., 19
**Электрон адрес:** e-mail: redak@list.ru
**Телефоннар**: 2-36-12 – җаваплы сәркатип, реклама бүлеге, факс
2-36-20 – рус бүлеге
2-36-13 - корреспондентлар
2-25-88 – бухгалтерия

**Нәшер итүче:**
"ТАТМЕДИА" АҖ 420097, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2.

Газета элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең Татарстан Республикасындагы (Татарстан) идарәсе тарафыннан 2013 елның 16 маенда теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы: ПИ № ТУ 16-01018
Бу сан "Татмедиа" АҖ филиалы
"Идел – Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды
Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2.
Басуга тапшыру вакыты: график буенча – 14.30, фактта – 14.30

татмедиа
Тираж - 1871

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин.
Редакциянең рәсми оешмаларда яклаучы булып чыгарга мөмкинлеге юк.
**Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.**
Реклама белдерүләренең төгәллеге өчен реклама бирүче үзе җаваплы.

Газета **чәршәмбе** һәм **җомга** чыга.
Заказ №5951
Язылу индексы – 16185
Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.
12+


© Язмаларны күчереп бастыру редакциянең язмача рөхсәте белән генә мөмкин.